idelbue@ya.ru
http://idelbue.narod.ru

# МОҢНАР КАЙТСЫН АВЫЛГА

*РАМИЛ ЧУРАГУЛОВ көе*
*РИЗВАН ХАКИМОВ сүзләре*

Авыл киче. Тасмалардан
Әй, агыла ят моңнар.
Нинди моңсу, әллә инде
Телсез калган гармуннар?

*Кушымта:*
Әйт, авылым, кайда соң моң?
Моң кайда соң, әйт, урам!
Аулак өйле һәм гармунлы
Яшьлегемне сагынам.

Авыл киче ник соң моңсу,
Күңелем ник буш шулай?
Өй түрендә тальян гармун
Моң сагынып зар елый.

*Кушымта.*

Йөрәкләргә очкын салып
Гармунымда уйныймын.
Авылыма моңнар биреп
Урамнарны буйлыймын.

*Кушымта.*

Авыл киче. Яшь йөрәкләр
Гармун, моңга сусаган.
Сөю булып моңнар кайтсын
Авылыма яңадан!

*Кушымта.*